ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

03.11.2020

№ 894

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 6 июлендәге 559 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.12.2009 елдагы 1934 номерлы карарына, Хөкүмәтнең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 18 июлендәге 840 номерлы карарына таянып, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 6 июлендәге 559 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасының җирле звеносы турындагы нигезләмәгә (алга таба-ҖЗ турында нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

ҖЗ турында Нигезләмәнең 4 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «объект дәрәҗәсендә - гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре, алар вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре керә.»

ҖЗ Нигезләмәсенең 1 нче кушымтасының 2нче пунктында «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә» сүзләрен «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

24 пунктның 23 абзацына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «гадәттән тыш хәлләр, аларның параметрлары һәм масштаблары, халыкның һәм территорияләрнең иминлеген тәэмин итү чаралары, яклау алымнары һәм ысуллары, гадәттән тыш хәл зонасында гамәлләр тәртибе, тәртип кагыйдәләре, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм зыян күрүчеләрне социаль яклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары турында, шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган түләүләрне алу хокукы, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә югалган документларны торгызу тәртибе турында халыкка мәгълүмат бирү.»

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү

территориаль системасының җирле звеносы турында» 2016 елның 20 маендагы 313 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин